**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү тәртибе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү тәртибе турында» 2008 елның 5 сентябрендәге ПУ-445 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 17 апрелендәге ПУ-211 номерлы, 2010 елның 18 августындагы ПУ-536 номерлы, 2012 елның 24 июлендәге ПУ-617 номерлы, 2012 елның 6 сентябрендәге ПУ-745 номерлы, 2013 елның 6 мартындагы ПУ-199 номерлы, 2013 елның 11 декабрендәге ПУ-1211 номерлы, 2015 елның 23 мартындагы ПУ-305 номерлы, 2015 елның 7 октябрендәге ПУ-973 номерлы, 2016 елның 22 февралендәге ПУ-200 номерлы, 2017 елның 14 гыйнварындагы ПУ-7 номерлы, 2017 елның 21 августындагы ПУ-719 номерлы, 2018 елның 27 ноябрендәге ПУ-805 номерлы һәм 2020 елның 22 июнендәге ПУ-359 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) преамбулада «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 18 статьясындагы 7 пунктның «а» пунктчасы һәм «Россия Федерациясе субъектларының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен координацияләү турында» Федераль закон» сүзләрен «Россия Федерациясе субъектларының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен координацияләү турында» 1999 елның 4 гыйнварындагы 4-ФЗ номерлы Федераль закон һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясы 1 пункты» сүзләренә алмаштырырга;

3 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсенә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта:

беренче абзацта «Министрлыкларга» сүзеннән соң «, дәүләт комитетларына» сүзләрен өстәргә;

өченче абзацта «Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсенә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү мәсьәләләре буенча даими эш төркеме (алга таба – эш төркеме) составында:

эш төркеме составыннан А.Ә. Кәримовны чыгарырга;

эш төркеме составына Коробченко Олег Владимировичны – Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министрын кертергә;

эш төркеме әгъзалары вазыйфалары атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Ә.Ә. Сәфәровның – «Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе Җитәкчесе, эш төркеме җитәкчесе»;

Г.Т. Бакировның – «Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе»;

Л.Ю. Глухованың «Татарстан Республикасы Рәисенең Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы»;

А.И. Нәфыйгинның – «Татарстан Республикасы Рәисе ярдәмчесе»;

Э.И. Хәбибуллинның – «Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты директоры»;

М.Р. Шаһиәхмәтовның – «Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы икътисад министры»;

в) Татарстан Республикасы яисә Татарстан Республикасы Хөкүмәте исеменнән кул куелучы шартнамәләр, килешүләр һәм башка актлар проектларын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәдә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге Нигезләмә Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, «Россия Федерациясе субъектларының халыкара һәм тышкы икътисадый элемтәләрен координацияләү турында» 1999 елның 4 гыйнварындагы 4-ФЗ номерлы һәм «Россия Федерациясе субъектларында гавами хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге 414-ФЗ номерлы федераль законнарга таянып эшләнде.»;

4 пунктның икенче абзацында «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә алмаштырырга;

6 пунктта:

беренче абзацта «Татарстан Республикасы Президентына» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенә» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Тышкы элемтәләр департаменты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Тышкы элемтәләр департаменты» сүзләренә алмаштырырга;

12 пунктның беренче абзацында «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

13 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең» сүзләренә, «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Рәисе** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2023 ел, 10 февраль
№ 83